2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы җирлеге Ямаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

10 декабрь 2023 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү, торак пункт территориясен төзекләндерү, смета төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү .

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Ямаш авылы, Советская урамы,109А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С.Ларин